**СОВЕТ**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.07.2023 Кодаш авылы № 29-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 31.01.2019 елның 47-1 номерлы Кодаш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль законнары, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 гыйнварындагы 47-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Шакиров

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге
Советының 2023 елның «26» июленнән 29-1
номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кодаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында” 2019 елның 31 гыйнварындагы 47-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы карарына кертелә торган

ҮЗГӘРЕШЛӘР

1) 1 бүлекнең 1.3 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 бүлекнең 2.2 пунктында «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 5 бүлектә:

5.1 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.2 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.3 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.6 пунктын төшереп калдырырга;

4) 9 бүлектә:

9.2 пунктта «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.3 пунктының 5 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

9.5 пунктының 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 10 бүлекнең 10.3 пунктында «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре аппаратларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 11 бүлектә:

11.2 пунктындагы 2 абзацны төшереп калдырырга;

11.4 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

11.5 пунктын төшереп калдырырга;

7) 12 бүлекнең 12.1 пунктында:

дүртенче абзацта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

алтынчы абзацта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

җиденче абзацта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

жиденче абзацта «Россия Федерациясе субъекты законы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләренең» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, башка муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 13 бүлектә:

13.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.7. Мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу чаралары муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

13.8 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

13.9, 13.10, 13.11 пунктларын төшереп калдырырга;

9) 15 бүлектә:

15.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы(Рәисе) сүзләренә алмаштырырга (алга таба - Татарстан Республикасы Рәисе);

15.7 пунктта түбәндәге сүзләр өстәргә: «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

15.11 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

15.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.14. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге бүлекнең 15.7 пунктында күрсәтелгән бүләк торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»;

15.4, 15.5, 15.6, 15.8, 15.9, 15.10, 15.13 пунктларын төшереп калдырырга.

10) 18 пунктның 18 бүлегендә 18.5, 18.6., 18.7 пунктларын төшереп калдырырга;

11) 19 бүлектә:

19.1 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

19.2 пунктның 2 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

19.2 пунктчасының 6 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратын» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 20 бүлекнең 4 пунктында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

13) 22 бүлектә:

22.2 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

22.3 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 24 бүлектә:

24.2 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен;

«, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратын» төшереп калдырырга;

15) 27 бүлекнең 27.3 пунктындагы 1 пунктчасында түбәндәге сүзләр өстәргә: «яисә «коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты Администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан;»